Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шоморбаш авыл җирлеге составына керүче
Шоморбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

29 октябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Шоморбаш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре, тумыштан инвалид, беренче группа инвалид) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Шомырбаш авылындагы Совет, Северный, Мәктәп урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Шоморбаш авылына чишмя ремонтлау.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 124 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 80 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 80 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлеге составына керүче Шоморбаш авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шоморбаш авыл җирлегенең Шоморбаш авыл торак пунктында тору

урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре, тумыштан инвалид, беренче группа инвалид) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Шомырбаш авылындагы Совет, Северный, Мәктәп урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
- Шоморбаш авылына чишмя ремонтлау.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сафин И.Н.

Шоморбаш авыл җирлеге башлыгы: Сафин И.Н